БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«31» 03 2023 ел № 128

2023 елга гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең, гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен билгеләү турында

«Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең, гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен билгеләү методикасына, Россия Федерациясе Торак кодексының 49, 50, 51 статьяларына туры китереп, «Торак урынның бер квадрат метрының уртача исәп-хисап базар бәясен куллану турында» 2023 елның 30 мартындагы 26 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. 2023 елга гражданнарны аз керемле дип тану турында карар кабул итү өчен түбәндәге чик күрсәткечләрне билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күләмен түбәндәгечә билгеләргә:

1.1.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен - 407700 сум;
1.1.2. Ике кешедән торган гаилә өчен - 815400 сум;
1.1.3. Өч кешедән торган гаилә өчен - 1223100 сум;
1.1.4. Дүрт кешедән торган гаилә өчен - 1630800 сум;
1.1.5. Биш кешедән торган гаилә өчен - 2038500 сум;
1.1.6. Алты кешедән торган гаилә өчен - 2446200 сум;
1.1.7. Җиде кешедән торган гаилә өчен – 2853900 сум;
1.1.8. Сигез кешедән торган гаилә өчен - 3261600 сум.

1.2. Исәпләүләр нигезендә гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең чик күрсәткече күләме 7118,67 сум тәшкил итә:

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф. Хәйретдинов

Балтач район башкарма комитетының
2023 елның 31.03
128 номерлы карарына
кушымта

**2023 елга гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең, гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен билгеләү**

**МЕТОДИКАСЫ**

1. Найм шартнамәләре буенча торак урыннары бирү нормасы буенча торак урыннары алуның базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече (алга таба - исәп-хисап күрсәткече) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

СЖ = НП Х РС х РЦ, биредә

СЖ - базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече яки мөлкәт хакының чиге;

НП - гаиләнең бер әгъзасына торак урыны бирү нормасы;

РС - гаилә әгъзалары саны;

РЦ - әлеге муниципаль берәмлекнең уртача шартларына һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин ителешенә туры килгән торак бинаның бер квадрат метр мәйданының уртача исәп-хисап базар бәясе, ул Татарстан Республикасында торак урыны сатып алуга түләүсез субсидияләр исәпләү өчен тиешле федераль башкарма хакимият органы билгеләгән гомуми мәйданның бер квадрат метрының уртача базар бәясеннән артмый. (Балтач район башкарма комитетының 2023 елның 30 мартындагы 126 номерлы карары нигезендә 22650 сум тәшкил итә)

а) ялгыз яшәүче граждан өчен:
СЖ = 22650х 18 = 407700 сум
б) ике кешедән торган гаиләгә:
СЖ = 22650 х 36 = 815400 сум
в) өч кешедән торган гаиләгә:
СЖ = 22650 х 54 = 1223100 сум
г) дүрт кешедән торган гаиләгә:
СЖ = 22650 х 72= 1630800 сум
д) биш кешедән торган гаиләгә:
СЖ = 22650 х 90 = 2038500 сум
е) алты кешедән торган гаиләгә:
СЖ = 22650х 108 =2446200 сум
ж) җиде кешедән торган гаиләгә:
СЖ = 22650 х 126 = 2853900 сум
з) сигез кешедән торган гаиләгә:
СЖ = 22650 х 144 = 3261600 сум.

2. Граждан гаиләсенең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем күләменең иң чик күрсәткече:

ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1 - (1 + ПС) - КП) / (0,3 х РС), биредә

ПД - гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган һәм СЖ исәп-хисап бәясе буенча торак урын алу өчен агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле уртача айлык җыелма керемнең чик күрсәткече;

СЖ - социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны бирү нормасы буенча торак урыны алу өчен базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече;

ПС - бер айга кредит буенча процент ставкасы (унлы вакланма), (2023 елның

28 февраленә Россия Федерациясе Үзәк Банкы ставкасы елына 7,5%, ягъни 7,5/100/12 айга = 0,00625 айга);

КП - кредитның барлык вакыты буенча кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (айлар саны) (2023 елның 1 гыйнварына Россия Федерациясе Үзәк Банкы мәгълүматлары буенча 289,4 ай);

РС - гаилә әгъзалары саны;

0,7 - кредит суммасы белән фатир бәясенең чагыштырмасы;

0,3 - кредит буенча түләүнең гаиләнең айлык җыелма кереме белән чагыштырмасы.

**Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик күрсәткечен исәпләү**

| НП - торак урынның нормасы (кв. м) | СЖ - торак урын сатып алуның базар бәясе (СЖ = РС х РЦ х НП) (сум) | РС - гаилә әгъзалары саны (кеше) | РЦ - торак урынның 1 квадрат метрының базар бәясе (сум) | ПС - кредит буенча айлык процент ставкасы, % | КП - кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (ай) | Кредит суммасы белән фатир бәясенең чагыштырмасы | Кредит буенча түләүнең айлык җыелма керем белән чагыштырмасы | ПД - Керемнең чик күрсәткече (сум) (1 кешегә) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| | | | 22650 | 7,5/100/12= 0,00625 | 289,4 | 0,7 | 0,3 | |
| 18 | 407700 | 1 | 22650 | 0,00625 | 289,4 | 0,7 | 0,3 | 7118,67 |
| 36 | 815400 | 2 | 22650 | 0,00625 | 289,4 | 0,7 | 0,6 | 7118,67 |
| 54 | 1223100 | 3 | 22650 | 0,00625 | 289,4 | 0,7 | 0,9 | 7118,67 |
| 72 | 1630800 | 4 | 22650 | 0,00625 | 289,4 | 0,7 | 1,2 | 7118,67 |
| 90 | 2038500 | 5 | 22650 | 0,00625 | 289,4 | 0,7 | 1,5 | 7118,67 |
| 108 | 2446200 | 6 | 22650 | 0,00625 | 289,4 | 0,7 | 1,8 | 7118,67 |
| 126 | 2853900 | 7 | 22650 | 0,00625 | 289,4 | 0,7 | 2,1 | 7118,67 |
| 144 | 3261600 | 8 | 22650 | 0,00625 | 289,4 | 0,7 | 2,4 | 7118,67 |